| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 май г.Казань № 568

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадның реаль секторы предприятиеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренең пенсия тупланмалары дәрәҗәсен арттыру чаралары турында» 2005 ел, 23 декабрь, 548 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадның реаль секторы предприятиеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренең пенсия тупланмалары дәрәҗәсен арттыру чаралары турында» 2005 ел, 23 декабрь, 548 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта:

беренче абзацта «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «хезмәт пенсиясен» сүзләрен «иминият пенсиясен» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Инвестиция чараларын инвесторлар сыйфатында гамәлгә ашырганда һәм тәэмин итүчеләрне билгеләүнең конкурент ысулларын кулланганда оешмаларга түбәндәгеләрне тәэмин иткән хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеген игътибарга алуны тәкъдим итәргә:

инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара мөнәсәбәтләрен җайга сала торган шартнамә (контракт) төзү турында карар кабул ителгән яисә конкурс нигезендә сайлап алу үткәрелгән айга кадәрге соңгы өч ай эчендә пенсионерның яшәү

минимумыннан артыграк күләмдә иминият пенсиясен билгеләү мөмкинлеге бирә торган хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүнең минималь күләме;»;

өченче абзацта «карар» сүзен «карар кабул ителгән ай» сүзләренә алмаштырырга, «конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «конкурс нигезендә сайлап алу уздырылган» сүзләренә алмаштырырга;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә эш бирүчеләрнең хезмәткә түләүнең минималь күләмен саклауны тәэмин итү мәсьәләсе буенча Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиясе белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга тәкъдим итәргә.»;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин